**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2026 елның 07 июле** **58-РС номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль-шәхси партнерлык турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Советның 2017 елның 14 августындагы 51-РС нчы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 02 маендагы 132-ФЗ нчы Федераль законга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Советның «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль-шәхси партнерлык турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 14 августындагы 51-РС нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1)7 нче статьяны түбәндәге эчтәлекле 8 нче өлеш белән тулыландырырга: – «7.8. Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан, әлеге Федераль законның 16 нчы статьясының 2 нче өлешенең 2 нче пунктында күздә тотылган тәртиптә килешүләрнең тормышка ашырылуын мониторинглау максатыннан, Россия Федерациясе территориясендә төзергә планлаштырыла торган, тормышка ашырылучы һәм тормышка ашырылган килешүләр турындагы мәгълүматларны «Управление» дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертүнең тулылыгы, дөреслеге һәм вакытында башкарылуы тәэмин ителә».
Әлеге үзгәреш 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә, әмма аның рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән соң бер ай узганнан да иртәрәк түгел.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы-**
**Совет рәисе** **И.Ф. Зарипов**